Чаллы - дуслык каласы : [Яр Чаллы шәһәренең М. Җәлил исемендәге Үзәк китапханәсендә җирле халыкларның милли мәдәниятен һәм әдәбиятын чагылдырган «Чаллы - дуслар каласы» («Многоликие Челны») фестивале узды] // Көмеш кыңгырау. – 2026. – № 8 (5 март). – Б. 4.

# Чаллы – дуслык каласы






Алиса Фәрдиева фотолары.

**Дөньяда нинди генә милләт юк. Миңа шуларның унысын берьюлы бер сәхнәдә күрү бәхете тәтеде. һәр бала үз милләтенең исемен ишетеп, башын югары күтәреп, горурлык белән сәхнәгә атлады. Аларның сәхнә артында бер-берсе өчен борчылып торулары, чыгышлардан соң «Афәрин» дип каршы алулары милләтләребезнең дуслыгын күрсәтә.**

Без – төрле. Кемдер бүрек кигән, кемнеңдер башында таңкәләр чыңлый, кемдер ак һәм кызыл төстә балкыган күлмәкләрдән, ә кайберәүләр табигать төсләренә якын, тоныграк киемнәрдән иде. Марилар һәм чувашлар шаян такмаклары, Кавказ халыклары дәртле биюләре, башкортлар курай моңына кушылып тыпырдаулары белән тамашачыларны таң калдырды. Аларның барысын да бергә «Чаллы – дуслар каласы» исемле мәдәни-әдәби фестиваль җыйды.

Чит төбәкләрдә татарлыкларын онытмаган милләттәшләребез кебек, төрле милләт халыклары Татарстанда үз җыеннарын үткәрә, балаларын туган телгә өйрәтә, милли бәйрәмнәрен саклый. Без алар белән горурланабыз һәм бу изге эшләрен хөрмәт итәбез. Кеше кайда гына яшәсә дә, үз телендә фикердәш һәм иптәш кирәк. Күп вакытта милләтеңнең кадерен чит җирләргә чыгып киткәч кенә, иңнәреңә Татарстан әләмен ябып, әбиең пешергән өчпочмакны сагынып тилмергәндә генә тирәнрәк аңлыйсың ул.

Бәйрәмдә «Әдәби Чаллы», «Уйнап ачыла күңел», «Халыклар дуслыгы – әдәбият дуслыгы», «Уйнагыз гармуннар» кебек мәйданчыклар, шулай ук аш-су һәм кул эшләре буенча мастер-класслар узды.

Фестивальдә шулай ук «Моңлы ягым – Татарстан» иҗат бәйгесенә йомгак ясалды.



## Бәйге турында...

**Диләрә ЖИҺАНШИНА,**
*49нчы кадет мәктәбе:*

– Мин Муса Җәлилнең «Дару» шигырен сөйләдем. Бу конкурска әзерләнүдә сыйныф җитәкчем булышты. Фестиваль бик ошады, икенче елга да катнашачакмын.

**Әмир ТАХАУТДИНОВ,**
*16нчы мәктәп:*

– «Кызыл ромашка» шигырен сөйләп беренче урын алдым.

**Регина МИГМАНОВА,**
*39нчы мәктәп:*

– Фестивальдән яңа эмоцияләр һәм танышулар көтәм. Монда тәҗрибә алыр өчен килдем. Яңа шигырьләр һәм шагыйрьләр исеме ишеттем. Миңа бик кызык.